Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!

# Татарстан КОММУНИСТЫ

№9-10 (21-22). 2011 ел, 25 октябрь. КПРФның Татарстан региональ бүлеге иҗтимагый-политик газетасы

Барлык почта бүлекләрендә дә «ПРАВДА» газетасына язылырга мөмкин. Газетаның индексы: 50102. Ярты елга язылу бәясе: 634,44 сум.

## «КУРС — ҖИҢҮГӘ!»

**8 октябрь көнне Казанда В.И. Ленинның музей-йортында КПРФның Татарстан региональ бүлеге республика комитетының һәм контроль-ревизия комиссиясенең берләштерелгән VII (октябрь) пленумы булып үтте.**

Пленумның көн тәртибенә куелган «КПРФның чираттан тыш үткәрелгән XIV съезды һәм КПРФ Татарстан региональ бүлегенең XIX партконференциясе карарларын тормышка ашыру буенча КПРФның республика комитеты, җирле бүлекләр, башлангыч партия оешмалары һәм һәр коммунист алдында торган бурычлар турында» доклад белән КПРФның Татарстан региональ бүлеге беренче секретаре Хафиз Гаязович Миргалимов чыкты.

Пленумда шулай ук чыгыш ясадылар: Василий Николаевич Лихачев – хокук мәсьәләләре буенча Россия Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе председателе киңәшчесе, алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка КПРФтан күрсәтелгән кандидат (Казан округы буенча исемлектә беренче); Виктор Петрович Пешков – РФ Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе, алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка КПРФтан күрсәтелгән кандидат (Чаллы округы буенча исемлектә беренче); Мансур Зәйдуллович Гарифуллин – КПРФның Алабуга шәһәр комитеты беренче секретаре, алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка КПРФтан күрсәтелгән кандидат (Чаллы округы буенча исемлектә өченче); Илдус Хәбипович Камалов – Чаллы шәһәр Советы депутаты, алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка КПРФтан күрсәтелгән кандидат (Чаллы округы буенча); Валерий Владимирович Натальин – Бөгелмә шәһәр Советы депутаты, алтынчы чакырылыш РФ Дәүләт Думасына депутатлыкка КПРФтан күрсәтелгән кандидат (Чаллы округы буенча); Рафаил Фәттахович Нуретдинов – Татарстан Дәүләт Советы депутаты, социаль-экономик мәсьәләләр буенча КПРФның республика комитеты секретаре.

Ахырда пленум тиешле карарлар кабул итте. Карарда, аерым алганда, болай диелә:

КПРФ рескомы беренче секретаренең докладын тыңлап тикшергәннән соң, пленум халык мәнфәгатьләрен кайгыртып, үзгәрешләр кирәклеген яклап чыгулар, гражданнарның күпчелегендә яңа карашлар формалашу процессы баруны билгеләп үтә. Либерализм догмалары һәм советларга каршы пропаганда җимерелеп, юкка чыга, ә ил халкының күпчелеге СССРның юкка чыгуын үкенечле хәл дип бәяли.

РФ Коммунистлар партиясе халык мәнфәгатьләрен яклап көрәшә. Татарстан коммунистлары үз сайлаучылары белән актив эшлиләр, депутат-коммунистлар гражданнарның наказларын үтиләр һәм эчке оппозиция төркеменең төрлечә каршылыклар тудырырга тырышуларына карамастан, «Халык референдумы» кысаларында актив рәвештә имзалар җыялар, республика халкы арасында агитация һәм пропаганда эшләре алып баралар.

Хакимлек итүче режим Россия Федерациясенең Коммунистлар партиясен политик аренадан алып ташлау өчен барысын да эшли. КПРФның Татарстан рескомы VII (октябрь) пленумы региональ бүлектә үзләрен күпчелеккә каршы куя торган аерым бер коммунистлар төркеме булуын таный. Ул кешеләр теләсә нинди юллар белән, хәтта КПРФ Уставын бозудан да тайчанып тормыйча, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып, партия оешмасын таркатырга тырышалар.

Компартия сафларының бердәмлеген саклап калу максатында, пленум «КПРФның Татарстан республика бүлеге партия сафларының идея бердәмлеген күтәрү һәм оешканлыгын ныгыту турында» Мөрәҗәгать кабул итте.

КПРФ үз алдына сайлауларда җиңеп чыгу һәм алдагы 5-6 елда Россиядәге вәзгыятьне кискен үзгәртү, милли куркынычсызлыкны тәэмин итү, тизләтелгән экономик үсеш юлына чыгу, хәерчелекне һәм социаль деградацияне бетерү буенча кичектергесез ашыгыч мәсьәләләрне чишү бурычын куйды.

Партия референдумга хокук алу, башкарма хакимият эшенә парламент контроле булдыру, муниципаль берәмлекләр башлыкларын һәм судьяларны сайлап куюга ирешү өчен омтыла.

КПРФның XIV съезды илнең барлык патриотик көчләрен КПРФ тирәсендә тупланырга һәм берләшергә, халык тарафыннан власть рычагларын яулап алу, парламентта күпчелеккә ирешү, бөтенхалык президенты сайлау, халык ышанычын яулаган хөкүмәт булдыру өчен көрәшергә чакыра.

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы сайлауларда максимум бурыч – властьта хакимлек итүчеләр партиясен җиңеп чыгу.

Компартиянең лозунглары: «Оборона политикасыннан – бар халык һөҗүменә күчү!», «Күпчелекнең политикасы – җиңүгә курс!», «Олигархларны урлаганнарын кайтарып бирергә мәҗбүр итәрбез!».

Татарстан Республикасы коммунистларына һәм аларның тарафдарларына – Россия Федерациясе Дәүләт Думасы Федераль Җыенына алтынчы чакырылыш депутатлары сайлауда актив катнашырга; «Халык референдумы»ның йомгаклау фазасын үткәреп бетерү эшен көчәйтергә; КПРФның республика, шәһәр һәм район комитетларына – КПРФның XIV съезды материалларын һәм КПРФ Татарстан региональ бүлегенең сайлау алды платформасын таратырга; җирле бүлекләрнең сайлау штабларына – протест эшләрен оештырган вакытта яхшы сыйфатлы агитация һәм пропаганда материалларын әзерләп таратырга, сайлаучылар белән очрашулар һәм КПРФ кандидатларының күмәк мәгълүмат чараларында чыгышларын оештырырга.

Республика һәм урыннардагы җирле сайлау штабларына – Үзәк, территориаль һәм участок сайлау комиссияләренә хәлиткеч тавышка ия членлыкка кандидатлар тәкъдим итәр өчен тәвәккәл кешеләрне сайлап алырга, һәр сайлау участогына күзәтүчеләр билгеләргә, участок сайлау комиссияләре эшенә, тавыш бирүләрне үткәрүнең барышына, йомгаклау протоколларын алуга, сайлаулар процессының юридик ягына игътибар бирүгә контрольне көчәйтергә кушылды.

## Комсомолның оештыру җыелышы



Р. Гайфуллов һәм Г. Зюганов

Быелның 5 февралендә Мәскәүдә СКМның V съезды Россия Федерациясе Ленинчыл Коммунистик Яшьләр Союзын (ЛКСМ) оештыру турында карар кабул иткән иде. Анда КПРФ республика комитетының яшьләр эше буенча секретаре Рамил Гайфуллов җитәкчелегендә Татарстан комсомолы вәкилләре дә катнашты.

16 октябрь көнне Казанда Татарстан Республикасы буенча ЛКСМны оештыру җыелышы үткәрелде. Анда Казан, Чаллы, Әлмәт, Зәй, Азнакай, Биектау һәм Тәтештән килгән яшьләр җитәкче органнарны сайлады. Рамил Равилевич Гайфуллов ЛКСМның республика комитеты беренче секретаре булды. Ул Казанда туган, КГФЭИда югары белем алгач, «Татнефть» ААҖендә хезмәт юлын башлаган. Бүгенге көндә Роспотребнадзорның Татарстан республика идарәсендә әйдәр эксперт-белгеч булып эшли.

ЛКСМның оештыру җыелышында Казан шәһәр Думасының КПРФ фракциясе җитәкчесе Илгизәр Вәлиев катнашты һәм чыгыш ясады.

**КПРФ рескомы пресс-службасы**

## Центризбирком хәбәр итә

ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Анатолий Фомин әйтүенчә, Татарстанда барлыгы 2 мең 857 участок комиссиясе составына 20 мең кеше керәчәк.

3 ноябрьгә кадәр партияләр эфир вакытын бүлешәчәк. 5 ноябрьдә исә дебатлар башлана. Шул вакытта халык кайсы партиягә өстенлек бирәчәге хакында уйланырга тиеш тә инде. 10 ноябрьгә кадәр исә участок комиссияләре составы билгеләнәчәк. Татарстандагы сайлау кампаниясен 200гә якын матубгат чарасы яктыртачак. Татарстандагы сайлау кампаниясенә Мәскәү 150 миллион сумнан артык акча бүлеп биргән. Дөрес, башта бу сумма кимрәк булган, тик республикадагы 33 районда электрон тавыш бирү комплексын куллану үзгәрешләр кертергә мәҗбүр иткән. Әле бит ул җайланмалар белән эшләргә өйрәтәсе дә бар. Анатолий Фомин сүзләренчә, 2016 елга кадәр илдәге барлык участокларда да тавыш бирү тартмалары барлыкка киләчәк.

## *3нче чакырылыш РФ Дәүләт Думасы (2000-2003) депутаты, җәмәгать эшлеклесе Фәндәс Шакирович САФИУЛЛИН:*

*– Бездә сайлау юк инде ул. Билгеләү генә бар. Ә билгеләүчеләр Татарстанда, күп булса да, дүрт-биш кешедер. Кемнәр депутат буласы билгеле инде, тавыш бирәсе генә калды. Нәтиҗә дә билгеле. Татар халкына каршы законнар кабул иткән партияне калдырырга омтылалар. Аннан нәрсә көтәсең? Бездә туган телебезгә хуҗа булу хокукыннан мәхрүм иттеләр. Бу кайсы партия? Хәзер хакимияттә булган партия. Татарның милли мәгарифен, милли мәдәниятен юкка чыгардылар. Шул партия кала түгелме? Алдагы сайлауда җиңәргә омтылган һәм шуны җиңдерергә тырышкан шәхесләрдән нәрсә өмет итәргә? Халык уйлансын иде.*

## РФ алтынчы чакырылыш Дәүләт Думасы Федераль җыенына депутатлыкка «КПРФ» политик партиясеннән КАНДИДАТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

### Исемлекнең гомумфедераль өлеше:

1. ЗЮГАНОВ ГЕННАДИЙ АНДРЕЕВИЧ;
2. КОМОЕДОВ ВЛАДИМИР ПЕТРОВИЧ;
3. АФОНИН ЮРИЙ ВЯЧЕСЛАВОВИЧ;
4. АЛФЕРОВ ЖОРЕС ИВАНОВИЧ;
5. САВИЦКАЯ СВЕТЛАНА ЕВГЕНЬЕВНА;
6. МЕЛЬНИКОВ ИВАН ИВАНОВИЧ;
7. КАШИН ВЛАДИМИР ИВАНОВИЧ;
8. ЧЕРКЕСОВ ВИКТОР ВАСИЛЬЕВИЧ;
9. НОВИКОВ ДМИТРИЙ ГЕОРГИЕВИЧ;
10. ТАЙСАЕВ КАЗБЕК КУЦУКОВИЧ.



**Геннадий Андреевич ЗЮГАНОВ**

1944 елның 26 июнендә Орел өлкәсе Хотынецкий районы Мымрино авылында укытучылар гаиләсендә туган. 1963-1966 елларда Совет армиясендә хезмәт итә, запастагы подполковник. 1966 елдан КПСС члены. 1969 елда Орел пединститутын тәмамлый. Философия фәннәре докторы. I-V чакырылыш РФ Дәүләт Думасы депутаты.

1972-1974 елларда – ВЛКСМның Орел өлкә комитеты беренче секретаре.

1974-1983 елларда – КПССның Орел өлкә комитеты секретаре, өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1983-1990 елларда – КПСС Үзәк Комитетының пропаганда һәм агитация бүлегендә эшли.

1990 елдан – РСФСР компартиясе Үзәк Комитеты Политбюросы члены һәм секретаре, 1995 елдан – КПРФ Үзәк Комитеты председателе.

# РФ алтынчы чакырылыш Дәүләт Думасы Федераль җыенына депутатлыкка «КПРФ» политик партиясеннән КАНДИДАТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

## 16нчы региональ төркем (Татарстан – Казан)

**1. ЛИХАЧЕВ ВАСИЛИЙ НИКОЛАЕВИЧ.** Туган көне – 1952 ел, 5 гыйнвар; туган урыны – Түбән Новгород шәһәре; яшәү урыны – Мәскәү шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Россия Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе аппараты» иҗтимагый берләшмә учреждениесе, хокук мәсьәләләре буенча Россия Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе председателе киңәшчесе.

**2. КИМ ОЛЕГ ЧАНБОКОВИЧ.** Туган көне – 1952 ел, 28 май; туган урыны – Ташкент өлкәсе, Аккурган районы, Солдат авылы; яшәү урыны – Түбән Новгород шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Нижегороддрапс» ҖЧҖ, генераль директор; даими булмаган нигездә Түбән Новгород шәһәре Думасы депутаты, «КПРФ» политик партиясе члены.

**3. МИРГАЛИМОВ ХАФИЗ ГАЯЗОВИЧ.** Туган көне – 1954 ел, 14 август; туган урыны – Татарстан АССР, Чирмешән районы, Бәркәтә авылы; яшәү урыны – Чаллы шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, депутат, дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә эшләре буенча комитет председателе урынбасары; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлеге комитетының беренче секретаре.

**4. САЛИХОВА РАЗЫЯ МИНҺАҖЕВНА.** Туган көне – 1948 ел, 5 март; туган урыны – Ульяновск өлкәсе, Чардаклы районы, Янганай авылы; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Казан вертолет заводы» ААҖ, участок мастеры; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлеге Казан шәһәре бүлекчәсенең комитет члены.

**5. КОСТРИН ВАЛЕНТИН ИВАНОВИЧ.** Туган көне – 1945 ел, 24 февраль; туган урыны – Татарстан АССР, Зеленодольск шәһәре; яшәү урыны – Зеленодольск шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Зеленодольск «Лифт» предприятиесе» ААҖ, генераль директор; даими булмаган нигездә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлеге комитеты секретаре.

**6. ПЕТРОВ ЮРИЙ НИКОЛАЕВИЧ.** Туган көне – 1961 ел, 31 июль; туган урыны – Татарстан АССР, Чистай шәһәре; яшәү урыны – Чистай шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – вакытлыча эшләми; Әфганстан сугышында һәм башка локаль конфликтларда катнашу нәтиҗәсе инвалидларының Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмасы Чистай шәһәр бүлеге Советы председателе.

**7. БИКМУЛЛИН АЛЬБЕРТ ЛОТФУЛЛОВИЧ.** Туган көне – 1939 ел, 31 июль; туган урыны – Казан шәһәре; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – Татарстан Республикасы Информатизация академиясе, президент; даими булмаган нигездә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты.

**8. РЫБАКОВ ФОАТ ЙОСЫФОВИЧ.** Туган көне – 1953 ел, 25 декабрь; туган урыны – Татарстан АССР, Буа районы, Әдәп-Толымбай авылы; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – пенсионер; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлеге комитеты секретаре.

**9. СИМОНОВ АНТОН ВЛАДИСЛАВОВИЧ.** Туган көне – 1988 ел, 28 август; туган урыны – Казан шәһәре; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – гомуми урта белемле; төп эш урыны – КПРФ Татарстан региональ бүлеге республика комитеты, партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге инструкторы; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлегенең Казан шәһәре Совет райкомы секретаре.

## 17нче региональ төркем (Татарстан – Чаллы)

**1. ПЕШКОВ ВИКТОР ПЕТРОВИЧ.** Туган көне – 1945 ел, 28 октябрь; туган урыны – Караганда шәһәре; яшәү урыны – Мәскәү шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – Россия Федерациясе Дәүләт Думасы аппараты, депутат ярдәмчесе; «КПРФ» политик партиясе члены.

**2. ПРОКОФЬЕВ АРТЕМ ВЯЧЕСЛАВОВИЧ.** Туган көне – 1983 ел, 31 декабрь; туган урыны – Казан шәһәре; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – Россия Федерациясе Дәүләт Думасы Федераль Җыены аппараты, депутат ярдәмчесе; даими булмаган нигездә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты; «КПРФ» политик партиясе әгъзасы, Үзәк Комитет членлыгына кандидат.

**3. ГАРИФУЛЛИН МАНСУР ЗӘЙДУЛЛОВИЧ.** Туган көне – 1960 ел, 14 апрель; туган урыны – Пермь өлкәсе, Кизел шәһәре; яшәү урыны – Алабуга шәһәре; белеме – урта һөнәри; төп эш урыны – «Җилемле модуль конструкцияле йорт төзү комбинаты» ЯАҖ, электромонтер; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлегенең Алабуга шәһәр бүлекчәсе беренче секретаре.

**4. НАТАЛЬИН ВАЛЕРИЙ ВЛАДИМИРОВИЧ.** Туган көне – 1961 ел, 11 май; туган урыны – Оренбург өлкәсе, Северный районы, Секретарка авылы; яшәү урыны – Бөгелмә шәһәре; белеме – урта һөнәри; төп эш урыны – «КПРФ» политик партиясе республика комитеты аппараты, партия-оештыру эшләре буенча инструктор; даими булмаган нигездә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы, «Бөгелмә шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлеге республика комитеты бюросы члены.

**5. ГЫЙЛӘҖЕВ ХӘКИМ МИРГАЛИМОВИЧ.** Туган көне – 1955 ел, 18 май; туган урыны – Татарстан АССР, Азнакай районы, Урсай авылы; яшәү урыны – Азнакай шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «КПРФ» политик партиясе Татарстан региональ бүлеге, «Татарстан коммунисты» газетасы баш редакторы; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлегенең Азнакай шәһәр бүлекчәсе комитеты беренче секретаре.

**6. АГАФОНОВ АЛЕКСАНДР ФЕДОРОВИЧ.** Туган көне – 1959 ел, 21 март; туган урыны – Архангельск өлкәсе, Онега шәһәре; яшәү урыны – Әлмәт шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Әлмәт дәүләт нефть институты» югары һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча ректор ярдәмчесе; даими булмаган нигездә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлегенең Әлмәт шәһәр бүлекчәсе комитеты беренче секретаре.

**7. ФӘЙЗРАХМАНОВ ИРЕК РАФАИЛЕВИЧ.** Туган көне – 1968 ел, 24 апрель; туган урыны – Казан шәһәре; яшәү урыны – Казан шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Стройгазпроект Плюс» ҖЧҖ, директор; даими булмаган нигездә Казан шәһәр Думасы депутаты; «КПРФ» политик партиясе члены.

**8. КАМАЛОВ ИЛДУС ХӘБИПОВИЧ.** Туган көне – 1944 ел, 1 гыйнвар; туган урыны – Татарстан АССР, Чистай районы, Кутлушкино авылы; яшәү урыны – Чаллы шәһәре; белеме – югары һөнәри; төп эш урыны – «Кама Инженерлык Үзәге «Синергия» ҖЧҖ, генераль директор; даими булмаган нигездә «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы депутаты; «КПРФ» политик партиясе члены, Татарстан региональ бүлегенең Чаллы шәһәр бүлекчәсе контроль-ревизия комиссиясе председателе.

## Лихачев Василий Николаевич

(КПРФтан Казан төркеме исемлеген җитәкли)




1952 елда Горький шәһәрендә туган, В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган. 1975-1988 елларда – КДУ аспиранты, ассистенты, доценты. Юридик фәннәр докторы, профессор. 1982-1983 елларда – Гвинея-Бисау Республикасында, 1987-1988 елларда – Мадагаскар Демократик Республикасында укытучы.

1988-1990 елларда – КПССның Татарстан өлкә комитеты дәүләти-хокук бүлеге мөдире. 1990-1991 елларда – Татарстанның Конституцион күзәтчелек комитеты председателе. 1991-1995 елларда – ТР вице-президенты. 1995-1998 елларда ТР Дәүләт Советы председателе. 1996–1998 елларда – РФ Федераль Җыены Федерация Советы председателе урынбасары. 1998–2003 елларда Брюссельдә (Бельгия) Европа Советының РФдан даими вәкиле. 2004-2010 елларда – Ингушетиядән РФ Федерация Советы вәкиле. 2010–2011 елларда – РФ юстиция министры урынбасары. Бүгенге көндә – Россия Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе председателе киңәшчесе.

## Пешков Виктор Петрович

(КПРФтан Чаллы төркеме исемлеген җитәкли)



1945 елда Караганда шәһәрендә туган. Мәскәү авиация технология институтын, Бөтенсоюз юридик читтән торып уку институтын һәм Россия идарә итү академиясен тәмамлаган. Психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы. 1986-1990 елларда — КПССның Мәскәү шәһәре Свердловск район комитеты бүлек мөдире һәм секретаре. 1990-1991 елларда — РСФСР Компартиясе Үзәк Комитеты бүлегенең гуманитар һәм идеология проблемалары консультанты. 1992-1994 елларда — Халыкара «РАУ-Корпорация» хөкүмәттән тыш фәнни-тикшеренү оешмасының Европа гуманитар программалар институты консультанты. 1994-1995 елларда — РФ Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе. 1995-2003 елларда икенче һәм өченче чакырылыш Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутаты. Бүгенге көндә КПРФ Үзәк Комитетының сайлау алды кампанияләрен үткәрү комиссиясе председателе. Россия политик культурасын өйрәнү үзәге члены. КПРФ Үзәк Комитеты председателе киңәшчесе.

## Миргалимов Хафиз Гаязович

(КПРФтан Казан төркеме исемлегенә кертелгән)



1954 елда Татарстанның Чирмешән районы Бәркәтә авылында туган. 1972-1974 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. Аннан соң В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында укый. 1981 елдан – комсомол-партия эшендә: «Камдорстрой» трестында комсомол секретаре, КПССның Чаллы шәһәре Комсомол райкомы оештыру бүлеге мөдире. 1992 елдан – «Челныгорстрой» ААҖнең төрле тармакларында җаваплы эшләрдә. 2005 елдан III-IV чакырылыш ТР Дәүләт Советының даими нигездә эшләүче депутаты, КПРФ фракциясе җитәкчесе. Дәүләт Советы Президиумы члены, ТР Дәүләт Советының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты председателе урынбасары.

2004 елга кадәр – КПРФның Комсомол райкомы һәм Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре, аннан соң – партиянең Татарстан рескомы беренче секретаре, КПРФ Үзәк Комитеты члены.

## Гыйләҗев Хәким Миргалимович

(КПРФтан Чаллы төркеме исемлегенә кертелгән)



1955 елда Татарстанның Азнакай районы Урсай авылында туган. 1980 елда В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Шул елдан коммунистлар партиясе члены. Укытучы, мәктәп директоры, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә методист һәм директор булып эшләгән. 2000-2005 елларда Азнакай район-шәһәр берләштерелгән Советы депутаты. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе һәм «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медале белән бүләкләнгән. Хезмәт ветераны. 2010 елдан «Татарстан коммунисты» республика газетасының баш редакторы булып эшли. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Журналистлар союзы члены. ТРның «Алтын йөрәкле журналист» дипломы иясе.

КПРФның республика комитеты члены, Азнакай шәһәр комитетының беренче секретаре. КПРФ Үзәк Комитеты медальләре һәм «Партийная доблесть» ордены белән бүләкләнгән.

# Бүген компартия чын-чынлап җиңеп чыга ала!

**Дәүләт Думасына депутатлыкка Татарстаннан кандидатлар КПРФның сайлау алды программасын тәкъдим иттеләр.**

КПРФның Татарстан региональ бүлеге республика комитеты бинасында Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидатлар катнашында матбугат конференциясе үтте. Анда ике региональ төркем лидерлары: Казан төркеменнән – В.Н. Лихачев, Х.Г. Миргалимов һәм Чаллы төркеменнән – В.П. Пешков белән А.В. Прокофьев катнаштылар.

КПРФның Татарстан региональ бүлегеннән ике исемлектә барлыгы – 17 кандидат.



*Сулдан уңга: В. Пешков, Х. Миргалимов, В. Лихачев һәм А. Прокофьев*

## Василий Лихачев: «Мин өч нәрсәгә өстенлек бирәм: ышаныч, үзара аңлашу һәм эш»

Конференциядә катнашучылар алдында кереш сүз белән В.Н. Лихачев чыгыш ясады. Ул илнең бик авыр хәлдә икәнлеген, вәзгыятьнең федераль һәм региональ дәрәҗәдәге күмәк мәгълүмат чаралары сөйләгәннәргә туры килмәвен әйтеп узды.

«Үз вакытында хокукый-дәүләт бүлегенең (КПССның Татарстан өлкә комитетында) СССРда иң яшь мөдире идем. Геннадий Андреевич Зюганов белән мөнә 23 ел дуслар без. КПРФның сайлау алды программасында мине прагматика җәлеп итә, эшне гамәлгә ашыруны этаплап башкару планы ошый. КПРФ курсы түбәндәгеләрдән тормышка ашырылачак: ул алда торган сорауларга ачык һәм төгәл җаваплардан тора – яңа тышкы политик курс буенча; яңа экономик политика курсы буенча; яңа социаль политика буенча. Бу бурычлар барысы да үзара тыгыз бәйләнгәннәр. Алар сайлау алды программасының төп принциплары булып торалар», – дип ассызыклап әйтте кандидат.

«КПРФ программасына дипломатлар, Евросоюз политтехнологлары һәм хәтта көнбатышның махсус службалары да игътибарларын юнәлттеләр, чөнки анда Россия Федерациясенең хәзерге заман шартларында алга хәрәкәт итүенең реаль юллары күрсәтелгән. Зюгановның 24 сентябрь көнне КПРФның XIV съездында ясаган докладында прагматик җаваплар бирелгән. Компартия, тарих сабакларын истә тоткан хәлдә, алга карап эшли», – диде В.Н. Лихачев.

«Мин республикага үземнең яңа эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирә торган планнарымны, инвестицион проектларымны алып килдем. Бу сорауларны республика җитәкчелеге белән очрашуларда да күтәрәчәкмен. Мин өч нәрсәгә өстенлек бирәм: ышаныч, үзара аңлашу һәм эш», – дип, үзенең уй-ниятләре белән дә уртаклашты кандидат.

«Яңа Дума составында безне нинди бурычлар көтә соң? Алар күп. Беренче планда – закон чыгаруда инициативалы булу. Мисал өчен, совет заманнары традицияләренең һәм КПССның эш практикасыннан гамәлләрнең иң яхшыларын гына алу, патриотик тәрбия турында федераль закон әзерләү», – дип билгеләп үтте чыгыш ясаучы.

«Коррупциягә каршы рәхимсез көрәшергә кирәк, ул дәүләт организмын ашап-җимереп килә. Россия, дөньядагы башка илләр белән чагыштырганда, бу күрсәткеч буенча 174нче урында тора. Җинаятьләр Кодексына конфискацияләү турындагы инде онытылып беткән статьяны кабат кайтару кирәк. Мин халыкара дәрәҗәле юрист, әле дә булса бер нәрсәне төшенә алмыйм: БМО Конвенциясенең 20нче статьясы (законсыз юл белән баю) ни өчен бүгенге көнгә кадәр ратификацияләнмәгән? Аны ратификацияләү турындагы тәкъдимне КПРФ фракциясе керткән иде. Ни өчен без Җинаятьләр Кодексына милекне конфискацияләү турындагы статьяны кертмибез? Ул статья Кодекстан 2003 елда алып ташланган иде. Дөрес, 2006 елда кире кертелде ул, әмма бик тә аңлаешсыз рәвештә. Бүгенге көндә бу статья эшләми», – дип сөйләдә В.Н. Лихачев КПРФның хокук өлкәсендәге тәкъдимнәренең берсе турында.

Журналистларның алда торган сайлауларда региональ бүлекнең перспективалары турындагы сорауларына җавап биреп, В.Н. Лихачев Татарстан коммунистларының яңа Дума составына 4-5 депутат үткәрергә ният итүләрен әйтте.

## Виктор Пешков: «Иртәгәсе көн өчен курку булырга тиеш түгел»

Кара-каршы сөйләшүне кандидатларның Чаллы региональ төркемен җитәкләүче В.П. Пешков дәвам иттерде. «Иртәгәсе көн өчен курку булырга тиеш түгел! Бу куркуны бетенләй бетерергә, кеше күңелендә килачәккә ышаныч уятырга тиешбез – алтынчы Дәүләт Думасы составында КПРФның төп бурычы бу», – дип басым ясап әйтте кандидат.

«Илдәге хәл тотрыклы түгел, ул, образлы итеп әйткәндә, асты өскә әйләндереп, капкачына гына бастырып куелган минераль су шешәсенә охшаган – тышкы яктан әз генә бер кискен тәэсир көче булуга, бу конструкция җимерелеп төшәчәк. Ил зәгыйфьләнмәсен өчен безгә закон чыгару органнарында коммунист-депутатларның мөмкин кадәр күбрәк санда булуларына ирешү кирәк. Россиядә политик монополизмны – бер генә партия властен җиңеп чыгу – КПРФның сайлау алды программасын гамәлгә ашыруның зарури шарты. Яңа Дума составында Татарстан вәкилләре дә булсын өчен барысын да эшләргә кирәк», – дип, В.П. Пешков сайлау алды кампаниясенең төп бурычларыннан берсен аерып күрсәтте.

## Артём Прокофьев: «Бүген Компартия чын-чынлап җиңеп чыга ала!»

КПРФ Үзәк Комитетының информацион-аналитик бүлек мөдире урынбасары, политик технологияләр бүлеге мөдире, депутатлыкка кандидат А.В. Прокофьев үз чыгышында компартия фракциясенең Дәүләт Думасындагы эшчәнлеген кыскача гына тасвирлап бирде һәм соңгы сайлаулар нәтиҗәләреннән берничә мәгълүмат китерде. «Коммунистлар, – дип билгеләп үтте ул, – РФ Президенты булуның вәкаләтле срогын 6 елга кадәр озайтуга каршы тулы составта (57 депутат) тавыш бирделәр. КПРФ Президент өчен дә, Дәүләт Думасы өчен дә вәкаләт срогын бер төрле итеп, 5 ел дип билгеләргә, яисә, президент вәкаләтләрен 6 елга кадәр озайткан очракта, аның икенче срокка сайлануын бөтенләй бетерергә тәкъдим иткән иде, әмма «единоросс»лар Дәүләт Думасында гына түгел, ә профиль комитетында да купчелеккә ия булу сәбәпле, бу тәкъдимне кире кактылар.

Бүген компартия чын-чынлап җиңеп чыга ала. Соңгы елларда ил буенча без сайлауларда уртача 20 проценттан артыграк тавыш җыябыз. Менә КПРФның агымдагы елның март аенда узган муниципаль сайлауларда җиңүе күрсәткечләре: Түбән Новгород, Арзамас, Ржев, Тверь, Киров шәһәрләре. Кировта иң яхшы нәтиҗә коммунистларныкы булды. Алар барлык тавышларның 36 процентына ия булдылар», – дип, кандидат РФ коммунистлар партиясенең уңышлары турындагы хәбәрләр белән уртаклашты.

«18 сентябрьдә Нижгар өлкәсенең Выкса шәһәрендә муниципаль сайлаулар булып узды. Властьтагы партияне узып китеп, коммунистлар анда 34,41 процент тавыш җыйдылар. Ситуация болайрак: без баскыч арты баскыч буйлап югарыга күтәреләбез! Бердәнбер реаль оппозицион партия буларак, без уникаль урынга урнаша алдык, чөнки җәмгыятьтәге бөтен ихтыяҗны чагылдырабыз, сорауларга җавап табып бирәбез. Бу – лозунглар түгел, ә партия эшенең конкрет коралы-инструменты, яңа составтагы Думага кабул итәргә кирәк булачак закон проектларыбыз да әзер инде», – дип билгеләп үтте А.В. Прокофьев.

## Хафиз Миргалимов: «Закон тантана итәргә тиеш. Кешеләр бу властьтан арыдылар инде»

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының КПРФ фракциясе җитәкчесе, партиянең республика комитеты беренче секретаре Х.Г. Миргалимов үз чыгышында журналистлар белән очрашуда барган сөйләшүләргә йомгак ясады. «17 июльдә, – диде ул, – Түбән Новгородта Халык ополчениесе төзелде».

«Чынлыкта сайлаулар алдыннан коммунистларның һәм партиясезләрнең куәтле сул центристик блогын формальлаштыра башлауга старт бирелде, әмма шунысын да билгеләп үтү кирәк, узган елның октябрендә муниципаль берәмлекләрнең КПРФтан сайланган 146 депутатның 75е – партиясезләр. Дәүләт Думасы сайлауларына КПРФның федераль исемлегендә лидер булып торучыларның берсе адмирал В.П. Комоедов шулай ук партиясез кеше, әмма бу аның партия тормышында бик актив катнашуына, шул исәптән, Үзәк Комитет линиясе буенча Татарстанга куратор булып торуына да һич комачаулык итми», – дип ассызыклады ул үз чыгышында.

«Безгә намуслы сайлаулар хакында берниндн килешүләр дә төзергә кирәк түгел. Власть үзе законны сакласын. Закон тантана итәргә тиеш. Кешеләр бу властьтан арыдылар инде!» – дип, нәтиҗә ясады Х.Г. Миргалимов.

# Зона семинар-киңәшмәләре

15-16 октябрьләрдә Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә партия активының зона семинар-киңәшмәләре булып узды. Аларда федераль сайлауларга әзерлек мәсьәләләре тикшерелде. Бу көннәрдә участок сайлау комиссияләренә хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән члennар туплау эше бара. Сайлауларда киңәш бирү хокукына ия члennар һәм күзәтүчеләр дә кирәк булачак. Бу эшләр Бөгелмә, Алабуга, Лениногорск, Тәтеш, Азнакай, Әлмәт шәһәрләрендә вакытында башкарыла.

И.Г. Веселов сайлаулар буенча үзенең судлашу тәҗрибәсе белән уртаклашты. 2009 елда ул Казан шәһәренең 6нчы округы буенча Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат була. Әлеге округта сайлауга килмәүчеләр өчен урнага күплән бюллетень ташлау факты теркәлә. Кешеләр сайлауга бармый калса, хакимияттәгеләргә бюллетеньнәрне үзләренчә әвештәвеш китерергә юл ачыла.

Казанда чыгыш ясап, депутатлыкка кандидат В.Н. Лихачёв халык өчен бушлай юридик консультация пункты ачылачагын белдерде.

Депутатлыкка кандидат В.П. Пешков, халык безнең өчен тавыш бирергә әзер, ләкин ул тавышларны югалтмый саклап калу өчен участокларда контрольне тиешенчә оештырга иң җитди эш итеп карарга кирәк, диде.

Депутатлыкка кандидат А.В. Прокофьев сайлауларда алда торган бурычларны саннарда аңлатты, узган сайлаулар белән чагыштырганда нәтиҗәне икеләтә арттыру зарурлыгын әйтте.

КПРФның хокук мәсьәләләре буенча реском секретаре Ф.Ю. Рыбаков, сайлау участогында эш тәмамлану белән сайлау нәтиҗәләре турында протоколны политик партия өчен сорап алырга кирәклегенә басым ясады. Сайлау законнары бозылу фактлары булганда, участок сайлау комиссиясе члennары «Аерым фикер» («Особое мнение») формасында ул хакта әлеге протоколга язып имзасын куярга тиеш, диде ул.

Семинар-киңәшмәләр зур активлык белән үтте. Аларда шулай ук Татарстан Дәүләт Советының КПРФ фракциясе депутатлары Х.Г. Миргалимов, В.И. Кострин һәм Р.Ф. Нуретдиновлар чыгыш ясады.

Соңыннан партия активистларына КПРФ Үзәк Комитетының «М.В. Ломоносовка 300 ел» истәлек медальләре тапшырылды.

**Илсур ФАТЫЙХОВ, Татарстан Үзәк сайлау комиссиясенең КПРФтан киңәш бирү хокукына ия члены.**

# Сайларга өйрәтәләр

Сайлау участогына барып, бюллетень алу белән, яныңа килеп басалар да сине өйрәтә башлыйлар: кемне сайларга, тамганы кайсы урынга куярга... Тамга куя торган җиргә ияреп кереп, кулыңа каләм биреп, урынын күрсәтеп чыгалар. Шулай буладыр инде демократларча сайлау?! Анда ике милиция хезмәткәре дә утыра, алар бер сүз дә эндәшми. Мин алар дөреслек яклы, дип уйлый идем, алай түгел икән. Фикерем үзгәрде. Шушы яшемә җитеп (Минсабир абый 1937 елгы. *Редакция искәрмәсе*), андый сайлау күрергә туры килмәде. Хәерле булсын!

**Минсабир ХӘСНУЛЛИН.**

# Мин профсоюздан нигә чыктым?

Халык байлыгына кызыгып күзләре кызарган түрәләр, илебездәге социалистик системаны җимереп, капитализм төзергә тотындылар. Ләкин совет системасын ничек кенә яманласалар да, аның үзләренә файдалы якларын саклап калырга тырыштылар.

**Бүген предприятиеләрдә җитәкче мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы профсоюз оешмалары барлыкка килде, минемчә.**

Әйе, җитәкчеләрнең дә төрлесе булган кебек, бөтен профсоюз председательләрен дә бер калыпка салып карарга ярамый. Эшчеләр үз теләкләре белән сайлап куйган профсоюз җитәкчеләре күп иде элек. Мәсәлән, Азнакай УБРы профсоюз председателе Әләм Хәнипов – шундыйлардан. Үз эшчеләрен, шулай ук, Азнакай халкын яклап йөргән өчен шәхси тормышында күпме киртәләргә очрады. Шулай булуга карамастан, күрәләтә кеше хокукларын бозучы түрәләргә каршы бүген дә бик актив көрәш алып бара.

Ләкин мондый үз эшенә бирелгән, чын профсоюз лидеры булу – бүген сирәк күренеш. Күп кенә предприятиеләрдә бу оешма эшче хокукларының бозылу очракларын яшереп калдыру өчен кирәк. Җитәкчеләр, профсоюз председателе имзасы булган кәгазь кисәген күрсәтеп, эшче хокуку бозылмавын исбатларга омтыла. Ләкин бу күп очракта дөреслеккә туры килми. Мин моны үзем эшләгән нефтьчеләр предприятиесе мисалында бик яхшы беләм.

Азнакай УТТсы (технологик транспорт идарәсе) февраль, март айларында байтак кына шоферларга хезмәт хакының бер сәгатьлек тарифын киметеп түләде. Ә Русия хезмәт законнары буенча моның өчен эшчене ике ай алдан имза куйдыртып, кисәтергә тиеш иде. Бозылган хокукыбызны яклауны сорап, мин УТТ профсоюз председателе Атлас Ганиевка мөрәҗәгать иттем. Апрель аеның хезмәт хакы дөрес тариф белән түләнде. Ләкин ике айлык түләнеп җитмәгән акчаларның кем кесәсенә кергәне аңлаешсыз калды. Русия законын, эшче хокукларын бозган өчен җавап тотучы да булмады. Бездә, эшчеләрне куркытып, «Хәзинә» газетасына яздыру гадәте бар. Һичьюгы, шул газетада хокуклары бозылган эшчеләрдән гафу үтенеп язган язма да күренмәде.

Ә бит профсоюзларның төп вазыйфасы – үз әгъзаларының хокукларын яклап чыгу. Ләкин бездәге профсоюз, предприятие өчен җыелыш алып бару, мәдәни яки спорт чаралары оештыру, бәйрәмнәрдә түрәләр күңелен күрү белән мәшгуль. Әйе, бүгенге профсоюзны эшче хокукларын яклаучы дип әйтеп булмый. Ул фәкать түрәләрнең кытыршы эшләрен шомартучы ролен генә үти.

Шулай булгач, нигә соң без аңа ай саен бер процент хезмәт хакыбызны биреп барабыз? Без түләгән акчага нигә түрәләр каядыр барып, балалары белән «качышлы уйнап» йөрергә тиеш? Капитализм чорында мондый профсоюзга таянып буламы, әллә безгә башка «хокук ярдәмчесе» оештырыргамы? Менә шундый уйлар мине бу союздан гариза язып чыгарга мәҗбүр итте. Бүгенге көндә мондый профсоюздан чыгарга теләүчеләр байтак. Ләкин, кубесен ипотека, кредит, ссуда кебек капитализм богаулары бәйләп тора. Чөнки бу адымың белән түрәләр күңеленә ярап бетмәвең бар.

Шул ук сәбәп безнең предприятиедә күп кенә шоферларны тәзек булмаган техника белән, «Булгария» теплоходы капитаны кебек, көн саен линиягә чыгып китәргә мәҗбүр итә. Запчасть янга калдырып, җитәкчеләрнең премия алуы бәрабәренә, күпләр тормышын куркыныч астына куеп, айлар буе ярык, яисә шомарган тәгәрмәч белән йөрергә мәҗбүр. Шоферларның хокукын бозып, шәхси машиналарында һәм гаражларында законсыз тентү оештырырга сәләтле булган УТТ хакимияте үзенең югары дәрәҗәдәге җитәкчеләренә, база территориясенә кертеп шәхси машиналарын куярга рөхсәт итә. Алар сак хезмәте тарафыннан да тикшерелми. Капкадан чыкканда нинди материал байлыклар алып чыкканнары да билгесез. Безнең профсоюз башлыгыбыз да шулар белән тиңләштерелгән. Бәлки, шул да эшче белән профсоюз арасын ерагайтуда күпмедер өлеш кертә торгандыр.

Хезмәт хакының торакка түләү, товар хакларыннан көннән көн ераклашуы да бүгенге профсоюзларның безнең өчен түгел икәнен раслый. Әйе, моны халык та аңлый, әйтик, үткән октябрь сайлаулары моны бик яхшы күрсәтте. Азнакайның иң эре нефть предприятиесе булган НГДУ профсоюзы рәисе моңа чаклы билгесез булган үз-үзен тәкъдим итүчегә оттырды. Ә бит ул, вакытында эшче хокукларын якларга тырышып йөрсә, халык аны сайламый калмас иде. Болай барса, алдагы сайлауларда да мондый сюрпризлар булырга мөмкин әле.

Сайлаулар якынлашкан бу көннәрдә ил, республика җитәкчеләре зирәклек күрсәтерләр, профсоюзлар эшчәнлегенә тәнкыйть күзлегеннән карап, яңа таләпләр куярлар, кискен чаралар күрерләр, дип өметләнәм.

**Рәшит САФИУЛЛИН, Азнакай шәһәр Советы депутаты, КПРФның шәһәр комитеты секретаре.**

**РЕДАКЦИЯДӘН.** Югарыда телгә алынган Әләм Хәмзә улы Хәнипов – «Татнефть» ААҖнең Мактаулы нефтьчесе. 1970 елларда Совет армиясе сафларында «Хәрби төзелеш отличнигы» исемен ала. 1975 елдан «Татнефть» системасында эшли. 1991 елдан – Азнакай УБРының (управление буровых работ) профком председателе. «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Россия профсоюзларына – 100 ел» медальләре, РФ Минтопэнерго Грамотасы белән бүләкләнгән. Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең Мактаулы члены. «Татнефть» профсоюзының Мактаулы алтын билгесе, «Татарстан профсоюзлар федерациясенең профсоюз хәрәкәте алдындагы хезмәтләре өчен» билгесе иясе.

Әләм Хәнипов, май аенда Татарстан прокуроры Кафил Әмиров Азнакайга килгәч, аңа гариза белән мөрәҗәгать итә. Июнь аенда Азнакай шәһәр һәм Татарстан Югары судларына яклау сорап гариза бирә. Барысы да Ә. Хәниповның хаклы булуын таный һәм аны эшендә калдырырга дигән карарлар чыгара. Әмма «Татнефть» түрәләренең прокуратура һәм суд карарларына әллә ни исләре китми, дөреслек өчен көрәшүче Ә. Хәниповны эш урынына кертмиләр, гомерен хезмәт кешесен яклауга багышлаган мөхтәрәм зат урамда тилмереп йөри.

Күптән түгел, хаксызга кыерсытылган профсоюз лидеры, яклау сорап, РФ Дәүләт Думасына КПРФтан депутатлыкка кандидат, РФ Бәйсез Профсоюзлар Федерациясе председателе киңәшчесе В.Н. Лихачевка язма рәвештә мөрәҗәгать итте.

# Думага сайлаулар: барыргамы, бармаскамы?

«Левада» үзәге уздырган тикшеренүдә катнашкан 40% кешенең тиздән сайлаулар булачагын бөтенләй белмәгәне ачыкланды. Телевидение аша декабрьдә узачак сайлаулар турында даими сөйләнсә дә, аның өч айдан булачагы хакында бары тик 60% кеше генә хәбәрдар.

«Левада» үзәгенең мөдир урынбасары Алексей Гражданкин: «Дәүләт думасына сайлаулар турында сорый башласаң, күпләре «Нинди сайлау тагын? Мартта түгелмени соң алар?» дип җавап кайтарганнарын әйтә. Халык хакимият барыбер президент кулында икәнен белә. Думага сайлаулар аларны кызыксындырмый, алар аны күз буяу икәнен аңлый», ди Гражданкин.

Кешеләргә шулай ук «Русиягә Дәүләт думасы кирәкме?» дигән сорау белән дә мөрәҗәгать иткәннәр. 47% кеше «Әйе, кирәк» дип җавап биргән, ләкин 32% кеше «Кирәкми» дип өздереп әйткән. Алар фикеренчә, ил белән идарә итү өчен президент фәрманнары да бик җитә. Билгеле, һәр кешенең үз фикере булырга мөмкин, әйтик, берәү бюллетеньне үзе белән алып китәргә, икенчесе бармайча калырга мөмкин, әмма тавыш биреп кайтсаң да, берни үзгәрмәячәк. Үзләре теләгән шәхесләрне, фиркаләрне үткәрәчәкләр, кирәкле күләмдә тавышны да санап чыгачаклар, нәтиҗәдә, иске төркемнәрнең хакимлек итүе дәвам итәчәк.

**Римма Бикмөхәммәтова.**
(«Азатлык» радиосы. 16.09.2011.)

# Сайлаучы фикере

Сайлаудан берни өмет итмим. Барысы да халыкның үзеннән генә тора. Депутатлар кәнәфи һәм күбрәк акча эшләү өчен генә сайлана. Алар бернәрсә дә үзгәртә алмый. Чөнки әйтеләсе сүзләр әйтелгән инде. Минем фикеремчә, депутатлар кул күгәрү өчен генә кирәк. Шуңа күрә сайлауларга бармыйм да. Тормышны үзгәртү – һәркемнең үз кулында. Мин, мәсәлән, түрәләрдән бернәрсә дә көтмим. Үз тормышыңны үзең көйләмәсәң, синә беркем дә ярдәм итмәячәк.

**Гөлзада САФИУЛЛИНА, Татарстанның халык артисты.**

## Сайлаучылар сүзе

# Ишексез балкон



2009 елда ук Актүбә бистәсенең 5 катлы бер йортында матурлык өчен генә балконнар эшләп куйганнар иде. Беренче каттагы 16 фатир тәүге тапкыр балконлы булу бәхетенә ирешә. Әмма аларның ишекләре булмаганлыктан, бирелә яшәүчеләргә тәрәзә тупсасы аша сикереп йөрергә туры килә икән.

Әлеге 20нче йорт бистәнең Комаров урамында урнашкан. Бирелдәге идарә итүче компания озакка сузылган капиталь ремонт белән шөгыльләнде. Әмма алар балконнарны ишексез калдырып дигән уй беркемнең дә башына килмәгәндер.

– Кайда гына мөрәҗәгать итеп карасак та, безгә ачык кына җавап бирүче булмады, – ди шундый фатирда яшәүче Миләүшә Латыйпова. – Мондый балконнар өчен акча түккәнче, торбалар һәм батареяларны алыштырсалар, яхшырак булыр иде.

Мөмкинлеге булган кешеләр, стенаны кисеп, балконга ишек уеп өлгергән инде. Өлкән яшьтәгеләр һәм очын-очка ялгап яшәүчеләр, әлбәттә, моны эшли алмый.

Актүбәдәге әлеге уникаль күренеш турында мин «Комсомольская правда» гәзитендә дә язып чыккан идем. Икенче көнне үк адәм ышанмаслык бу манзараны күрергә Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләреннән төзелеш эшләре буенча компетентлы белгечләр килеп җиткән. Әмә менә Актүбә бистәсе башлыгы Р. Галиева сүзләренә караганда, әлеге ишексез балконнар турындагы хәбәрне дөньяга чыгару кирәк булмаган икән, чөнки бу йортта яшәүчеләргә юк балконны бар итеп рәсмиләштерү мәшәкате өстәлгән.

**Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ. Азнакай районы.**
(«Мәдәни җомга», 24.06.2011 ел, 19 бит).




«Татарстан коммунисты» («Коммунист Татарстана»)
Баш редактор урынына – Рамил ГАЙФУЛЛОВ
Техник редактор – Дмитрий ДЕНИСОВ
Телефон: 9600623230, факс: (85592) 7-56-46
Электрон адрес: ursai55@rambler.ru,
www.kprf.ru («Коммунисты и российское общество»)

Газетаның учредителе: КПРФның Татарстан региональ бүлеге.
Учредитель һәм редакциянең адресы: 420012, а/я 3, Казан шәһәре, Маяковский урамы, 18/39, офис 10. Тел./факс: (843) 236-28-05, 238-00-38
Газета Элемтә, информацион технологияләр һәм күмәк коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республика идарәсендә ПИ №ТУ 16-00314 таныклыгы белән 19.02.2010 елда теркәлде.
Басарга кул кую вакыты: график буенча – 25.10.2011 ел, 10.00, кул куелды – 10.00.

«Бөгелмә типографиясе» ААҖ
423230, РТ, Бөгелмә шәһәре, Карл Маркс урамы, 32
Телефон: (85594) 4-85-49
Заказ 44. Тираж 30000.
Бәясе ирекле.